| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРМАН ХУҖАЛЫГЫ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

---

ПРИКАЗ БОЕРЫК

21.01.2020 г.Казань № 43-осн

Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау турында

Законнарга кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Лубян урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау турында» 2014 елның 5 маендагы 163-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2014 елның 05 маендагы 163-осн номерлы боерыгы белән расланган Лубян урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 8 ноябрендәге 624-осн номерлы.

3. Әлеге боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары И.Н.Зариповка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 21.01. 43-осн номерлы боерыгы белән расланды

# ЛУБЯН УРМАНЧЫЛЫГЫНЫҢ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ РЕГЛАМЕНТЫ

# КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты Луябн урманчылыгы чикләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу нигезе булып тора.

Урман хуҗалыгы регламенты Россия Федерациясе Урман кодексының 87 статьясының 7 өлеше, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу срокларын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерыгы нигезендә эшләнде.

Урман хуҗалыгы Регламентының гамәлдә булу чоры – 2024 елның 3 июленә кадәр.

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә түбәндәгеләр файдаланылды:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 8 ноябрендәге 624-осн номерлы боерыгы белән расланган 2012 елгы урман корылышы материаллары;

дәүләт урман реестры материаллары.

Регламентны эшләүче:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы.

Почта адресы: Ямашев пр., 37А й., Казан ш., 420124.

E-mail: Minleshoz@tatar.ru.

Сайт: Minleshoz.tatarstan.ru.

Тел. (843) 221-37-01.

Факс (843) 221-37-37.

Урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү Бөтенроссия урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру фәнни-тикшеренү институты федераль бюджет учреждениесе филиалы «Көнчыгыш Европа Урман-сынау станциясе» тарафыннан 2019 елның 7 октябрендәге 919000500 номерлы контракт нигезендә гамәлгә ашырылды.

## Россия Федерациясе закон актлары

Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – Россия Федерациясе Урман кодексы),

Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ Су кодексы),

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы),

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы),

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ законы).

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Янгын куркынычсызлыгы турында» ФЗ).

«Махсус сакланучы табигый территорияләр турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы федераль закон).

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы федераль закон).

«Геодезия, картография һәм киңлек мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 431-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 431-ФЗ номерлы федераль закон).

«Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турында» 1997 елның 19 июлендәге 109-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 109-ФЗ номерлы федераль закон).

“Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы федераль закон).

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы федераль закон).

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы федераль закон).

«Җир корылышы турында» 2001 елның 18 июнендәге 78-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 78-ФЗ номерлы федераль закон).

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы федераль закон).

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы федераль закон).

«Элемтә турында» 2003 елның 07 июлендәге 126-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 126-ФЗ номерлы федераль закон).

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 04 декабрендәге 201-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 201-ФЗ номерлы федераль закон).

«Орлыкчылык турында» 1997 елның 17 декабрендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон (149-ФЗ номерлы федераль закон).

«Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы федераль закон).

«Үсемлекләр карантины турында» 2014 елның 21 июлендәге 206-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 206-ФЗ номерлы федераль закон).

РФ Урман кодексында каралган хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар (2020 елның 1 гыйнварындагы булган торышында).

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары | | |
| 91 статьның 7 өлеше | Дәүләт реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү күләме һәм аны алу тәртибе турында» 2007 елның 03 мартындагы 138 номерлы карары |
| 100 статьяның 2 өлеше, 81 статьяның 38 пункты | Урман кишәрлекләренә һәм урманнардан файдаланганда барлыкка килә торган мөлкәт хокукларына китерелгән зыянны түләү. Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләү таксаларын һәм методикаларын раслау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга һәм аларда булган табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары |
| 96 статья, 81 статьяның 36 пункты | Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урман сагы), аны гамәлгә ашыру тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман сагын) гамәлгә ашыру турында нигезләмә раслау турында» 2007 елның 22 июнендәге 394 номерлы карары |
| 50 статьяның 3 өлеше | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының максималь күләмен билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләмен билгеләү турында» 2007 елның 22 июнендәге 395 номерлы карары |
| 73 статьяның 4 өлеше, 81 статьяның 27 пункты | Федераль мөлкәттәге урман ресурслары бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеген арендалау өчен урман кишәрлеге мәйданы бирәмлеге өчен түләү ставкалары билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектә булган урман кишәрлеген арендалау буенча урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы бирәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| 44 статья | Сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су объектын файдалануга тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында» 2006 елның 30 декабрендәге 844 номерлы карары |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 76 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 30 пункты | Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре буенча түләү. Федераль мөлкәттә, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтендә һәм муниципаль мөлкәттә торучы җирләрдә әзерләнә торган агач материалы бирәмлеге өчен түләү ставкаларын билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль мөлкәттә торган урман кишәрлеген арендалау буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| 16 статьяның 3 өлеше, 60.3 статья, 81 статьяның 17 пункты | Урманнарда санитар куркынычсызлык. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре турында» 2007 елның 20 маендагы 607 номерлы карары |
| 16 статьяның 3 өлеше, 53 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 16 пункты | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 30 июнендәге 417 номерлы карары; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны янгынга каршы кору чаралары турында» 2011 елның 16 апрелендәге 281 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары нәтиҗәсендә урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 1464 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары нәтиҗәсендә урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында» 2011 елның 17 маендагы 376 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннарын сүндерү планын һәм аның рәвешен эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 17 маендагы 377 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 18 августындагы 687 номерлы карары |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 22 статьяның 3 өлеше | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестиция эшчәнлеге. Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны үзләштерү турында өстенлекле инвестиция проектлары турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 23 февралендәге 190 номерлы карары |
| 6 статья | Урманнар урнашкан җирләр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман фонды җирләрен бүтән (башка) категория җирләренә күчерү турында документлар составы һәм аларны әзерләү тәртибе турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 48 номерлы карары |
| 105 статьяның 7 өлеше | Урман-парк зоналарында урнашкан урманнарның, яшел зоналарда урнашкан урманнарның функциональ зоналары | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман паркы зоналарының вазыйфаи зоналарын, урман паркы зоналарының, яшел зоналарның мәйданын һәм чикләрен билгеләү турында нигезләмә раслау турында» 2009 елның 14 декабрендәге 1007 номерлы карары |
| 13 статья | Урман инфраструктурасы | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яклаучы урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 17 июлендәге 1283-р номерлы күрсәтмәсе |
| 21 статья | Урман инфраструктурасына бәйле булмаган объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яклаучы урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар исемлеген раслау турында» 2013 елның 27 маендагы 849-р номерлы күрсәтмәсе |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары |
| 73.1 статьяның 6 өлеше, 81 статьяның 28 һәм 29 пунктлары | Дәүләт мөлкәтендәге яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен әзерләү һәм | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агач материалы әзерләү өчен дәүләт мөлкәтендәге яисә муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста катнашучыларның конкурс тәкъдимнәрен |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | төзү тәртибе | бәяләү кагыйдәләрен һәм тәкъдим ителгән шартларны бәяләү һәм агач материалы әзерләү өчен дәүләт мөлкәтендәге яисә муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста җиңүчене билгеләүгә нигез булган критерийларны раслау турында» 2019 елның 7 мартындагы 241 номерлы карары |
| Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы (алга таба – Россия Табигать ресурслары министрлыгы) норматив актлары | | |
| 62 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 21 пункты | Урманнарны торгызу. Урманнарны торгызу кагыйдәләре | «Урманнарны торгызу кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 25 мартындагы 188 номерлы боерык |
| 73.1 статьяның 7 өлеше | Урман кишәрлегенең типик аренда шартнамәсе | «Урман кишәрлекләре арендасының бертип шартнамәсен раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 693 номерлы боерык |
| 75 статьяның 7 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу турында типик шартнамә | «Урман утыртмаларын сату-алуның бертип шартнамәсен раслау турында» 2017 елның 17 октябрендәге 567 номерлы боерык |
| 60.15 статья | Сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләре | «Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә РФ субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 29 маендагы 264 номерлы боерык |
| 16 статьяның 3 өлеше, 64 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 23 пункты | Урманнарны тәрбия кылу. Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | «Урманнарны карау кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 ноябрендәге 626 номерлы боерык |
| 112 статьяның 6 өлеше, 81 статьяның 40 пункты | Махсус сакланучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләре | «Махсус саклануча табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында» 2007 елның 16 июлендәге 181 номерлы боерык |
| 53.1 статья | Урман янгыннарын кисәтү | «Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләрен, урманнардан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителү нормативларын, |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | урманнардан файдаланганда булырга тиешле урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары нормаларын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 161 номерлы боерык |
| 53.2 статья | Урманнарда янгын чыгу куркынычын һәм урман янгыннарын мониторинглау | «Урманнарда янгын куркынычын һәм урман янгыннарын күзәтүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 июнендәге 276 номерлы боерык |
| 15 статьяның 3 өлеше | Урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар | «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерык |
| 87 статьяның 7 өлеше, 81 статьяның 34 пункты | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдә булу вакыты һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерык |
| 60.5 статья | Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы | «Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 апрелендәге 156 номерлы боерык |
| 60.7 статья | Зарарлы организмнар таралуны кисәтү | «Зарарлы организмнар таралуны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 12 сентябрендәге 470 номерлы боерык |
| 60.6 статьяның 4 өлеше | Урман патологиясе буенча тикшеренүләр. Урман патологиясе буенча тикшеренүләр уздыру тәртибе | «Урман патологиясе буенча тикшеренүләр уздыру тәртибен һәм урман патологиясе буенча тикшеренү актының формасын раслау турында» 2016 елның 16 сентябрендәге 480 номерлы боерык |
| 16.1 статьяның 4 өлеше, 29 статьяның 9 өлеше, 81 статьяның 4 пункты | Диләнке эшләре. Агач материалы әзерләү. Агач материалы әзерләү кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | «Агач материалы әзерләү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда, урман паркларында агач материалы әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 474 номерлы боерык, «Диләнке эшләре төрләрен, аларны уздыру тәртибен һәм эзлеклелеген, Диләнке эшләренең технологик картасы формасын, Диләнке карау акты формасын һәм Диләнке карау тәртибен раслау |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | турында» 2016 елның 27 июнендәге 367 номерлы боерык |
| 60.4 статья | Урман яклау буенча районнарга бүленеш | «Урман яклау буенча районнарга бүлү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерык |
| 91 статья | Дәүләт урман реестры | «Дәүләт урман реестрына документлаштырылган мәгълүматлар кертүгә һәм аны үзгәртүгә нигез булган документларның исемлеген, аларның формаларын һәм аларны әзерләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 ноябрендәге 496 номерлы боерык,<br>«Дәүләт урман реестрында булган, зарури тәртиптә бирелә торган мәгълүматлар төрләре исемлеген һәм аны бирү шартларын раслау турында» 2013 елның 30 октябрендәге 464 номерлы боерык,<br>«Дәүләт урман реестрын алып бару рәвешләрен раслау турында» 2016 елның 06 октябрендәге 514 номерлы боерык, |
| 70.1 статьяның 12 өлеше | Урман кишәрлекләрен проектлау | «Урман кишәрлегенең проект документациясе составына һәм аның эчтәлегенә карата таләпләр, аны әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 03 февралендәге 54 номерлы боерык |
| 60.13 статья | Урманнарны радиоактив пычранудан саклау үзенчәлекләре | «Урманнарның радиоактив пычрану зоналарында профилактика һәм тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 08 июнендәге 283 номерлы боерык |
| 65 статьяның 5 өлеше | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкчылыгы объектларын, урман орлыкчылыгы плантацияләрен, даими урман орлыклары кишәрлекләрен һәм шундый объектларны төзү һәм бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге 438 номерлы боерык,<br>«Урманның төп агач токымнарының урман үсемлекләренең районнарга бүленгән орлыкларын куллану тәртибен раслау турында» 2015 елның 17 сентябрендәге 400 номерлы боерык |
| 46 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 13 пункты | Урманнардан агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану. Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен | «Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 01 декабрендәге 528 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | файдалану кагыйдәләре | |
| 38 статья | Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану | «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 21 июнендәге 314 номерлы боерык |
| 49 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 14 пункты | Урманнардан файдалану турында хисап. Урманнардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнардан файдалану турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнардан файдалану турында хисап тапшыру формасын һәм тәртибен, шулай ук урманнардан файдалану турында электрон рәвештә хисап формасына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы 451 номерлы боерык |
| 66 статьяның 2 өлеше, 81 статьяның 25 пункты | Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисап. Урманнардан файдалану һәм урман үрчетү турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урман торгызу һәм урман үрчетү турында электрон рәвештәге хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы 452 номерлы боерык |
| 89 статья | Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза. Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза тәртибе | «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 496 номерлы боерык |
| 26 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 3 пункты | Урман декларациясе. Урман декларациясен тутыру һәм тапшыру тәртибе | «Урман декларациясе формасын, аны тутыру һәм тапшыру тәртибен, электрон рәвештә урман декларациясе форматына таләпләр раслау турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы боерык |
| 60 статьяның 3 өлеше, 60.11 статьяның 3 өлеше, 81 статьяның 20.1 пункты | Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап. Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап тапшыру тәртибе. Урманнарны яклау турында хисап. Урманнарны яклау турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнарны янгыннардан саклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны янгыннардан саклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны янгыннардан саклау турында электрон рәвештә хисап тапшыру форматына карата таләпләр, урманнарны яклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны яклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны яклау турында |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | электрон рәвештә хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 09 мартындагы 78 номерлы боерык |
| 60.8 статьяның 5 өлеше | Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү | «Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 23 июнендәге 361 номерлы боерык |
| 53.4 статья | Урман янгыннарын сүндерү | «Урман янгыннарын сүндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 08 июлендәге 313 номерлы боерык |
| 64.1 статьяның 2 өлеше | Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү | «Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү тәртибен һәм тиешле акт рәвешләрен раслау турында» 2019 елның 11 мартындагы 150 номерлы боерык |
| 86 статьяның 5 өлеше | Россия Федерациясе субъектының урман планы. Россия Федерациясе субъектының урман планы составы һәм аны әзерләү тәртибе | «Россия Федерациясе субъекты урман планының бертип формасын һәм составын, аны әзерләү һәм үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 692 номерлы боерык |
| 32 статья | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында» 2018 елның 16 июлендәге 325 номерлы боерык |
| 67 статья, 68 статья | Урманнарны тәртипкә китерү турында гомуми нигезләмәләр. Урман корылышының эчтәлеге | «Урманнарны тәртипкә китерү инструкциясен раслау турында» 2018 елның 29 мартындагы 122 номерлы боерык |
| 63 статьяның 2 өлеше, 81 статьяның 22 пункты | Урман үрчетү. Урман үрчетү кагыйдәләре | «Урманнарны үрчетү кагыйдәләрен, урманнарны үрчетү проекты составын, аны эшләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 28 декабрендәге 700 номерлы боерык |
| Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (алга таба – Рослесхоз) норматив актлары | | |
| 88 статьяның 2 өлеше | Урманнарны үзләштерү проекты Урманнарны үзләштерү проектының составы һәм аны эшләү тәртибе | «Урманнарны үзләштерү проекты составын һәм аны эшләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 29 февралендәге 69 номерлы боерык |
| 29 статьяның 5 өлеше, 81 статьяның 1 пункты | Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибе | «Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында турында» 2011 елның 27 маендагы 191 номерлы боерык |
| 39.1 статья | Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү | «Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | елның 19 июлендәге 308 номерлы боерык |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | «Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 10 июнендәге 223 номерлы боерык |
| 43 статья | Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану | «Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 27 декабрендәге 515 номерлы боерык |
| 31 статья | Чәер әзерләү | «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 24 гыйнварындагы 23 номерлы боерык |
| 39 статья | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 510 номерлы боерык |
| 34 статья | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | «Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 511 номерлы боерык |
| 40 статья | Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 23 декабрендәге 548 номерлы боерык |
| 41 статья | Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 21 февралендәге 62 номерлы боерык |
| 29 статьяның 6 өлеше, 81 статьяның 2 пункты | Агач материалы әзерләү. Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеге | «Үзагачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 513 номерлы боерык |
| 53 статьяның 4 өлеше, 53.1 статья, 81 статьяның 16 пункты | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. Урман янгыннарын кисәтү | «Урманнарны янгынга каршы кору нормативларын раслау турында» 2012 елның 27 апрелендәге 174 номерлы боерык, «Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, һава торышына карап, урманнарда табигый янгын куркынычы классификациясен |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | раслау турында» 2011 елның 5 июлендәге 287 номерлы боерык |
| Россия Федерациясе субъекты норматив актлары | | |
| 82, 83 статьялар | Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре. Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшыру | «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-880 номерлы Указы, «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге 531 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яки Татарстан Республикасының муниципальара әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2017 елның 29 августындагы 617 номерлы карары |
| | | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында шәхси ихтыяҗлар өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча гражданнар өчен түләү ставкалары билгеләү турында» 2017 елның 27 февралендәге 9-1/нпс номерлы карары |

# 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1.1. Урманчылыкның аталышы һәм урнашкан урыны

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Лубян урманчылыгы Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгыш өлешендә Кукмара административ районы территориясендә урнашкан. Кукмара ш.т.п. административ үзәге.

Урманчылык конторасы Лубян авылында урнашкан, ул республика башкаласы Казан шәһәреннән 214 чакрым һәм иң якын тимер юл станциясеннән 30 чакрым ераклыкта.

Урманчылыкның юридик һәм почта адресы: 422108, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Лубян авылы, Техникум урамы, 10 йорт.

Телефоннар: 2-32-60 код 8-855-57, факс: 2-31-66

E-mail: Lubyanskoe.Gku@tatar.ru

Урманчылык территориясенең төньяктан көньякка кадәрге озынлыгы – 14 чм, көнчыгыштан көнбатышка кадәр – 36 чм.

### 1.1.2. Урманчылыкның, кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы, урманчылык территориясенең районнар буенча бүленеше

Урманчылык территориясенең муниципаль берәмлекләр буенча бүленеше 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица

Урманчылык төзелеше

| т/с | Кишәрлек урманчылыкларының атылышы | Административ район | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Кукмара | 12966 |
| Урманчылык буенча барлыгы | | | 12966 |

Урманчылыкның урман фонды көнбатыш өлешендә урман биләмәсеннән һәм аерым-аерым торган урман кишәрлекләреннән гыйбарәт. Урманчылык территориясе буйлап Нократ, Лубян елгалары һәм күпләгән санда кече елгалар, чишмәләр ага.

Урманчылык республиканың аз урманлы өлешендә урнашкан. Урманчылык урнашкан җирнең урман белән каплану өлеше 69,0% тәшкил итә.

Урманчылык территориясе бүлеп күрсәтелгән Татарстан Республикасы 1 нче номерлы карта-схемада күрсәтелде.

1 нче номерлы карта-схема




Экспликация

| № | Урманчылыклар, Федераль әһәмияттәге МСТТ |
|---|---|
| 1. | Әгерже |
| 2. | Азнакай |
| 3. | Аксубай |
| 4. | Әлки |
| 5. | Әлмәт |
| 6. | Арча |
| 7. | Баулы |
| 8. | Биләр |
| 9. | Болгар |
| 10. | Бөгелмә |
| 11. | Буа |
| 12. | Алабуга |
| 13. | Зәй |
| 14. | Яшел Үзән |
| 15. | Арча |
| 16. | Кайбыч |
| 17. | Кәләй |
| 18. | Кама |
| 19. | Кызыл Йолдыз |
| 20. | Лаеш |
| 21. | Лениногорск |
| 22. | Мамадыш |
| 23. | Минзәлә |
| 24. | Түбән Кама |
| 25. | Нурлат |
| 26. | Идел буе |
| 27. | Шәһәр яны |
| 28. | Саба |
| 29. | Тәтеш |
| 30. | Чирмешән |
| 31. | Лубян |
| 32. | Идел-Чулман ДТБТ |
| 33. | Түбән Кама МП |

| | |
|---|---|
| **Башкала** | Киров |
| **Мәйдан** | 30-нче |
| - Барлыгы | 120 374 км²[1] |
| - Су | 0,5% |
| **Халык саны** | 36-нче |
| - Барлыгы | 1 341 265 кеше (2010) |
| - Халык тыгызлыгы | 11 |
| **Тулаем региональ продукт** | 50 |
| - Барлык, агымдагы бәядә | 160,2 млрд. сум (2010) |
| - Кеше башына | 107,2 мең сум |
| **Федераль округы** | Идел буе |
| **Икътисади районы** | Идел-Нократ |
| **Рәсми тел(ләр)** | рус теле |
| **Губернатор** | Игорь Васильев (в.б)[3] |
| **Законнар чыгару Җыелышы рәисе** | Владимир Быков[4] |

### 1.1.3. Урманчылык урманнарының урман үсү зоналарына, урманлы районнарга һәм урман яклау зоналарына һәм урман-орлык районнарына бүленеше

Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының “Россия Федерациясе Урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясе Урманлы районнар исемлеген раслау турында” 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы белән расланган урман үсү районнары бүленешенә ярашлы рәвештә урманчылык территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасының ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районына кертелгән (2 нче таблица).

2 нче таблица

Урманчылык урманнарының урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүленеше

| № | Кишәрлек урманчылыкларының атылышы | Урман үсә торган зоналар | Урманлы район | Урман яклау районнарына бүленеш зонасы | Урман-орлык буенча районнарга бүленеш зонасы | Урман кварталлары исемлеге | мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасы | Россия Федерациясе Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районы | Урман патологиясе буенча уртача куркыныч | Нарат өчен - 2, чыршы - 4, карагай - 3, имән - 2. | 1-126 | 12966 |
| Урманчылык буенча барлыгы | | | | | | | 12966 |

Урманчылык территориясенең һәм кишәрлек урманчылыкларының урман үсү районнарына һәм урманлы районнарга бүленеше 2 номерлы карта-схемада күрсәтелде.

2 нче номерлы карта-схема



### 1.1.4. Урманчылык урманнарының кварталлар яисә аларның өлешләре буенча максатчан билгеләнеше һәм яклаучы урман категорияләре буенча бүленеше, шулай ук яклаучы, эксплуатация һәм резерв урманнарын бүлеп чыгару нигезләре

3 нче таблица

Урманнарның максатчан билгеләнеше һәм яклаучы урман категорияләре буенча бүленеше

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчы-лыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Җәмгысе урманнар,** шул исәптән | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | 1 - 126 | 12966 | |
| | **Җәмгысе** | | **12966** | |
| Яклаучы урманнар, барлыгы | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Кварталлар: 31, 48, 49, 66, 67, 83-85, 95-97, 103-106, 111-113, 116-126, әлеге кварталларның бер өлеше: 3, 7, 15-17, 22, 24, 25, 27-30, 32, 39-41, 45, 46, 50, 55-64, 68, 72-74, 81, 82, 86, 90, 91, 102, 107-110, , 115 | 3373 | |
| | Җәмгысе | | 3373 | |
| шул исәптән | | | | |
| су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Әлеге кварталларның бер өлеше: 3, 7, 15-17, 22, 24, 25, 27-32, 39-41, 45, 46, 48, 55-59, 63, 64, 72-74, 81-84, 90, 91, 95, 96, 102-104, 106-111, 114, 115, 123-126 | 821 | Россия федерациясе Урман кодексы, Россия федерациясе Су кодексы, «Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 4 декабрендәге 201-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, файдаланыла торган урманнарга кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз |
| | Җәмгысе | | 821 | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | боерыгы, Россия Табигать министрлыгының «Урман корылышы күрсәтмәсен раслау турында» 2018 елның 29 мартындагы 122 номерлы боерыгы белән расланган Урман корылышы күрсәтмәсе |
| табигый һәм бүтән объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнар, барлыгы, шул исәптән: | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Әлеге кварталларның бер өлеше: 31, 48-50, 67, 68, 85, 86, 96, 97, 104, 105 | 316 | |
| | Җәмгысе | | 316 | |
| Яклагыч урман полосаларында урнашкан урманнар (тимер юл транспорты турында Россия Федерациясе законнары, автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында законнар нигезендә билгеләнгән тимер юлларга бүлеп бирелгән полосалар чикләрендә һәм автомобиль юлларының юл буе полосаларында урнашкан урманнар) | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Әлеге кварталларның бер өлеше: 31, 48-50, 67, 68, 85, 86, 96, 97, 104, 105 | 316 | Россия федерациясе Урман кодексы, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яки Татарстан Республикасының муниципальара әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2017 елның 29 августындагы 617 номерлы карары |
| | Җәмгысе | | 316 | |
| кыйммәтле урманнар барлыгы, шул исәптән: | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | Кварталлар: 66, 112, 113, 116-122, әлеге кварталларның бер өлеше: 31, 46, 48, 49, 60-64, 67, 83-85, 95-97, 103-106, 111, 123-126 | 2236 | |
| | Җәмгысе | | 2236 | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчы-лыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| эрозиягә каршы урманнар (җирләрне эрозиядән саклау өчен билгеләнгән урманнар) | Кишәрлек урманчылыклары буенча бүлмичә | 117-122 кварталлар, 124 нче квартал өлеше | 720 | «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | Җәмгысе | | 720 | |
| фәнни яки тарихи-мәдәни әһәмияткә ия урманнар | Кишәрлек урманчылыклары буенча бүлмичә | Әлеге кварталларның бер өлеше 46, 60-64 | 120 | «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | Җәмгысе | | 120 | |
| су объектлары буйларында урнашкан тыюлыклы урман полосалары | Кишәрлек урманчылыклары буенча бүлмичә | Кварталлар: 66, 112, 113, әлеге кварталларның бер өлеше: 31, 48, 49, 67, 84, 85, 95-97, 104-106, 123, 124, 126 | 1072 | «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | Җәмгысе | | 1072 | |
| уылдык саклаучы урман полосалары | Кишәрлек урманчылыклары буенча бүлмичә | Квартал: 116, әлеге кварталларның бер өлеше: 83, 95, 103, 104, 111, 123, 125 | 324 | «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | Җәмгысе | | 324 | |
| Эксплуатация урманнары | Кишәрлек урманчылыклары буенча бүлмичә | Кварталлар: 1, 2, 4-6, 8-14, 18-21, 23, 26, 33-38, 42-44, 47, 51-54, 65, 69-71, 75-80, 87-89, 92-94, 98-101, әлеге кварталларның бер өлеше: 3, 7, 15- | 9593 | «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | 17, 22, 24, 25, 27-30, 32, 39-41, 45, 46, 50, 55-64, 68, 72-74, 81, 82, 86, 90, 91, 102, 107-110, 114, 115 | | елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | Җәмгысе | | 9593 | |

## 1.1.5. Урманчылык территориясендә урман фонды җирләре составыннан урманлы һәм урмансыз җирләргә сыйфатлама

4 нче таблица

Урманчылык территориясендә урман фондының урманлы һәм урмансыз җирләренә сыйфатлама

| Җирләрнең сыйфатлама күрсәткечләре | Урманчылык буенча барлыгы | |
|---|---|---|
| | мәйданы, га | % |
| 1 | 2 | 3 |
| Җирләрнең гомуми мәйданы | 12966 | 100 |
| Урманлы җирләр – барлыгы | 12330 | 95,1 |
| Урман үсемлекләре каплаган җирләр – барлыгы | 12048 | 92,9 |
| Шул исәптән урман культуралары | 5676 | 43,8 |
| Урман үсемлекләре капламаган җирләр – барлыгы | 282 | 2,2 |
| шул исәптән | | |
| – тоташмаган урман культуралары | 135 | 1,1 |
| – урман питомниклары; плантацияләр | 38 | 0,3 |
| – табигый аралыклар | – | – |
| – урман торгызу фонды, барлыгы | 109 | 0,8 |
| шул исәптән | | |
| – көекләр | – | – |
| – һәлак булган утыртмалар | 4 | – |
| – кисентеләр | 99 | 0,8 |
| – ачык, ташландык урыннар | 6 | – |
| Урмансыз җирләр – барлыгы | 636 | 4,9 |
| шул исәптән | | |
| – сөрүлекләр | – | – |
| – печән чабу урыннары | 59 | 0,4 |
| – җәйләүләр | 20 | 0,2 |
| – сулар | 124 | 1,0 |
| – бакчалар, тут агачлыклары, җиләклекләр | – | – |
| – юллар, ызаннар | 205 | 1,6 |
| – утарлар һ.б. | 55 | 0,4 |
| – сазлар | 119 | 0,9 |
| – комнар | 42 | 0,3 |

| | | |
|---|---|---|
| – башка төрле җирләр | 12 | 0,1 |

## 1.1.6. Гамәлдәге һәм проектлана торган махсус саклanучы табигый территорияләргә һәм объектларга, аларны оештыру, экологик челтәрләрен үстерү, биотөрлелеген саклау планнарына сыйфатлама

Хокукый режим Россия Федерациясе Урман кодексының 112 статьясы белән билгеләнә. Бу җирләр әйләнештән алынган яки әйләнешендә чикләнгән (Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясы).

Махсус саклanучы табигый территорияләрдә тыела яисә рөхсәт ителә, гамәлгә ашырыла торган конкрет эшчәнлек төрләре, шул исәптән урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау яисә яңадан җитештерү өлкәсендә, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Урман кодексы, «Махсус саклanучы табигый территорияләр турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль закон, шулай ук аларны үтәү өчен чыгарылган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Урманчылык территориясендә гамәлдәге һәм проектлана торган түбәндәге махсус саклanучы табигый территорияләр бар.

Махсус саклanучы табигый территорияләр исемлеге

| № | Махсус саклanучы табигый территориянең аталышы. Аерып чыгару нигезе | Объектның мәйданы, га | Кишәрлек урманчылыгы, квартал, бүлемтек | МСТТ профиле | Кыскача сыйфатлама һәм хуҗалык алып бару тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Гамәлдәге махсус саклanучы территорияләр | | | | | |
| 1. | Табигать һәйкәле – Лубян елгасы һәм аңа терәлеп торучы 100 метрлы полоса. (ТАССР Министрлар Советының 13.08.1987 № 344 карары) | 120 | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә, квартал өлешләре: 46, 60-64 | Комплекслы (ботаник-геологик) | Ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасының зональ үсемлекчелек тибы булган урман биләмәсе. Терлек көтү, агачларны һәм куакларны кисү, корылмалар һәм төзелмәләр торгызу, терлек өчен утлавыклар һәм җәйге көтү урыннары ясау, грунт алу һәм сөрү, дарулык һәм техник чимал җыю, бәйләмнәр өчен чәчәкләр өзү, учак ягу, биваклар кору рөхсәт ителми. |
| Проектлана торган махсус саклanучы территорияләр | | | | | |
| Проектланмый | | | | | |

## 1.1.7. Илкүләм мирас буенча проектлана торган урманнарга сыйфатлама

Татарстан Республикасы территориясендә сыйфатламалары буенча илкүләм мирас урманнарына кертү өчен тиешле урманнар юк.

### 1.1.8. Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек төрләрен һәм буфер зоналары зурлыклары исемлеге

Биологик күптөрлелекне саклау – урман хуҗалыгы эшчәнлеген алып баруда зарури шарт. Ул яклаучы урманнарда, махсус сакланучы урман кишәрлекләрендә генә түгел, ә диләнке эшләре гамәлгә ашырылганда да тәэмин ителергә тиеш.

Урман кишәрлекләрендә кисү эшләре уздырылганда тереклек итү тирәлеге шартлары шактый үзгәрә. Үсеш алуның үзгәргән шартларында, яңа шартларга хас булганча, бары тик урман биоценозлары гына яши ала, шуңа күрә тереклек тирәлеген тамырдан үзгәртә торган тоташ кисүләр барышында биотопларны (биоценоз белән киңлекләрнең абиотик факторлары буенча беришлеләренә карата) максималь саклау мөһим.

Үсемлекләрнең һәм хайваннарның урман төрләре тереклек итә торган шартлар төрлелеген саклау өчен диләнкеләрне аерып чыгарганда һәм таксацияләгәндә әһәмиятле биотоплар (әһәмиятле объектлар) – кисү эшләре кагылмый торган һәм биотөрлелекне саклау өчен әһәмиятле булган, зур булмаган җир кишәрлекләре аерып чыгарыла, ә диләнкеләр эшләнгәндә, – саклана.

## 2.11. Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү урманнарны яңадан үстерү һәм урман үрчетү максатларында гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урман утыртмаларының утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре 2011 елның 19 июлендәге 308 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган.

Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә мөмкин.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урман урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела.

Хәзерге вакытта Саба урманчылыгы урманнары чикләрендә төп урман хасил итүче токымнар үстерелә торган даими урман питомниклары юк.

Россия Федерациясе Урман кодексының 72 статьясы нигезендә урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе ун елдан алып кырык тугыз елга кадәрле срокка төзелә.

Кишәрлек урманчылыклары буенча урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

## 2.12. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 43 статьясы нигезендә җайга салына.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән күләмнәре һәм урманчылыкларның кишәрлек урманчылыклары кисемендә урман кишәрлекләренең урнашкан урыны 5 нче таблицада чагылдырылды.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлекләре арендага бирелә яки үз вәкаләтләре чикләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары рөхсәтләре нигезендә бирелә. Урман кишәрлеген бирмичә генә урман фонды җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкарырга рөхсәт ителә, әгәр мондый эшләрне башкару урман утыртмаларын кисүгә, капиталь төзелеш объектларын төзүгә китермәсә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру урманнардан файдалану Рослесхозның 2010 елның 27 декабрендәге 515 номерлы боерыгы белән расланган Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану тәртибе нигезендә башкарыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатында урманнардан файдалана торган затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

файдаланыла торган урманнарны һәм аның янәшәсендәге урман кырыйларын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, сәнәгать, агач кисүдән калган, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, чүп-чарлардан даими рәвештә чистартып торуны;

җитештерү эшчәнлеге барышында җимерелгән юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзекләндерү элементларын торгызуны;

Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган, Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыруга бәйле объектларны тиешле эшләрне үтәү чорлары тәмамлану белән консервацияләүне яисә юк итүне һәм күрсәтелгән объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм (яки) эксплуатацияләү өчен файдаланылган җирләрне рекультивацияләүне;

аталган затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын һәм урман янгыннарын юкка чыгару, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрелүне;

сейсмик разведка эшләрен планлаштыру һәм үткәрү, шулай ук хәрәкәт составын һәм йөкләрне яңа урынга күчерү максатларында квартал ызаннары, урман юллары биләгән һәм урман утыртмалары белән капланмаган башка җирләрдән максималь рәвештә файдалануны.

Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урманнардан файдаланганда алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була.

Аталган агач материалы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агач материалын сату турында» 2009 елның 23 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә сатыла.

Россия Федерациясе Урман кодексының 73.1 статьясының 3 өлешендә Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урманнардан файдалану өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә агач материалы әзерләү өчен аукцион уздырмыйча урман кишәрлекләренең аренда шартнамәләрен төзү каралган.

Россия Федерациясе Урман кодексының 73.1 статьясының 3 өлешендәге 3 пунктында 43, 45 статьяларда каралган очракларда, дәүләт мөлкәтендәге яки муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе җир асты байлыкларыннан файдаланугa лицензия гамәлдә булган срокка төзелә.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны торгызуны һәм урман үрчетүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урман торгызу проектына яки урман үрчетү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кисәннән соң бер елдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урман үрчетү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырганда.

## 2.13. Урманнардан сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм сроклары

Россия Федерациясе Урман кодексының 44 статьясы нигезендә сусаклагычларны, башка төрле ясалма су объектларын, шулай ук гидротехника корылмаларын, елга портларын, причаллар төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану су законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман законнары нормаларында билгеләнгәнчә, Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урманнардан файдаланганда алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була.

Аталган агач материалы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды

җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агач материалын сату турында» 2009 елның 23 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә сатыла.

Россия Федерациясе Урман кодексының 72 статьясының 3 өлеше һәм 74 статьясының 3 өлеше нигезендә урман кишәрлекләре атап үтелгән максатларда дәүләт органнары карарлары нигезендә, аукционнар уздырмыйча гына, бер елдан алып кырык тугыз елга кадәрге чорга арендага тапшырыла.

Дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлекләре гражданнарга, юридик затларга Россия Федерациясе Урман кодексының 9 статьясы нигезендә сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү өчен бирелә.

Сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү өчен кишәрлек урманчылыклары буенча урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны торгызуны һәм урман үрчетүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урман торгызу проектына яки урман үрчетү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кискәннән соң бер еллдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урман үрчетү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырганда.

## 2.14. Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясы нигезендә линияле объектларга электр тапшыру линияләре, элемтә линияләре, юллар, торбаүткәргечләр һәм башка линияле объектлар, шулай ук күрсәтелгән объектларның аерылгысыз технологик өлешен тәшкил итүче корылмалар керә.

Урманнардан файдалануның әлеге төре Россия Федерациясе Урман кодексының 45 статьясында һәм 2011 елның 10 июнендәге 223 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрендә регламентлана.

Сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү өчен гражданнарга һәм юридик затларга урманчылыкның барча территориясе буйлап урман кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшыру аренда хокукында гамәлгә ашырылырга мөмкин, ә махсус яклanучы урман кишәрлекләрендә фәкать күрсәтелгән эшләрне урнаштыру ихтималының башка вариантлары булмаган очракта гына рөхсәт ителә.

Дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлекләре

гражданнарга һәм юридик затларга Россия Федерациясе Урман кодексының 9 статьясы һәм 73.1 статьясының 3 өлеше нигезендә аукцион уздырмыйча кырык тугыз елга кадәр бирелә.

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү максатларында, барыннан элек, урмансыз җирләр, ә урман кишәрлегендә андый җирләр булмаганда – торгызылмаган кисенте җирләре, янгыннан калган җирләр, бушлыклар, ачык урыннар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман утыртмалары үсә торган җирләр файдаланылырга тиеш.

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү максатларында арендага, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылган урман кишәрлекләрендә урман утыртмаларын кисү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Урманнардан файдалануның әлеге төрендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан шушы рәвешле файдаланганда алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (Россия Федерациясе Урман кодексының 20 статьясының 2 өлеше). Аталган агач материалын сату Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агач материалын сату турында» 2009 елның 23 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм линияле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны тудыру өчен билгеләнгән сак һәм санитар-яклау зоналарында урман утыртмаларын кисү күрсәтелгән зоналарда билгеләнгән режимга туры китереп гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналарның чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануда махсус шартлар билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә көчәнеше 1000 вольтка кадәр булган электр челтәрләре өчен түбәндәгечә саклык зонасы билгеләнә:

электр тапшыру буенча һава линияләре буйлап (биналарга кертү өлешендәге тармакларыннан тыш) җир өслегендә кырый үткәргечләр проекцияләреннән һәр ягыннан 2 метр ераклыкта торучы, параллель турылар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә (алар үз торышыннан читкә чыгып тормаганда);

җир астыннан электр тапшыручы кабель линияләре буйлап кырый кабельләрдән һәр ягыннан 1 метр ераклыкта торучы, паралелль турылар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә.

1000 В югары булган электр челтәрләренең саклык зонасы киләсе таблицага туры китереп билгеләнә.

Көчәнеше 1000 В югары булган электр челтәрләренең саклык зонасы

| Көчәнешнең проектта каралган номинал классы, кВ | Ераклыгы, метр |
|---|---|
| 1 кадәр | 2 |
| 1-20 | 10 |
| 35 | 15 |

| | |
|---|---|
| 110 | 20 |
| 150, 220 | 25 |
| 300, 500, +/- 400 | 30 |
| 750, +/- 750 | 40 |
| 1150 | 55 |

Торбаүткәргечләргә (алар нинди ысул белән салынган булса да) зыян салыну ихтималын булдырмас өчен саклык зоналары билгеләнә:

нефть, табигый газ, нефть продуктлары, нефть һәм ясалма углеводород газы транспортлаучы торбаүткәргеч трассалары буйлап, – торбаүткәргеч күчәрененең һәр ягыннан 25 метр ераклыкта узучы шартлы линияләр белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

сыегайтылган углеводородлы газлар, тотрыклы булмаган бензин һәм конденсат транспортлаучы торбаүткәргеч трассалары буйлап, – торбаүткәргеч күчәренең һәр ягыннан 100 метр ераклыкта уза торган шартлы линияләр белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

күптармаклы торбаүткәргеч трассалары буйлап – кырый торбаүткәргечләрнең күчәрләреннән югарыда күрсәтелгән аралыкларда уза торган шартлы линияләр белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

су асты кичүләре буйлап – кичүләрнең кырый тармаклары күчәрләреннән һәр ягыннан 100 метр аралыкта торучы параллель яссылыклардан гыйбарәт булган су өслегеннән төпкә кадәрге су тирәлегенең бер өлеше рәвешендә;

конденсатны саклау һәм газсызландыру савытлары, продукцияне аварияле рәвештә чыгара торган җир амбарлары тирәли – йомык линия белән чикләнгән, әлеге объектлар территорияләреннән һәр яклап 50 метр ераклыкта урнашкан җир кишәрлеге рәвешендә; продукцияне транспортка әзерләүче технологик җайланмалар, суырту һәм тутыру буенча төп һәм аралык насос станцияләре, резервуар парклары, компрессор һәм газ бүлү станцияләре, продукцияне үлчәү төеннәре, салу һәм бушату эстакадалары, газны җир астында саклау станцияләре, нефть, нефть продуктларын җылыту пунктлары тирәли – күрсәтелгән объектларның территорияләре чикләреннән һәр ягыннан 100 метр торучы йомык линияләр белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә (Магистраль торбаүткәргечләрне саклау кагыйдәләре (Россиянең Федераль тау һәм сәнәгый күзәтчелегенең 1992 елның 24 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган) (Россиянең Федераль тау һәм сәнәгый күзәтчелегенең 1994 елның 23 ноябрендәге 61 номерлы карары редакциясендә).

Аерып чыгару полосаларының чикләре аерып чыгару полосасын формалаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләрен аерып чыгаруның Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы раслаган нормаларын исәпкә алып билгеләнә.

Аерып чыгару полосаларының һәм саклык зоналарының зурлыклары Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2008 елның 6 августындагы 126 номерлы боерыгында билгеләнгән Тимер юлларны аерып чыгару полосасын формалаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләрен аерып чыгару нормалары, шулай ук тимер юлларның саклык зоналарын исәпләп чыгару нормалары, җир корылышы, шәһәр төзелеше һәм проект документациясе, тимер юл линияләрен, төеннәрен һәм

станцияләрен үстерүнең генераль схемалары нигезендә, шулай ук барлыкка килгән җирдән файдалану тәртибен һәм аерып чыгару полосаларының һәм саклык зоналарының элегрәк расланган зурлыкларын һәм чикләрен исәпкә алып билгеләнә.

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге кишәрлек урманчылыклары буенча әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны торгызуны һәм урман үрчетүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урман торгызу проектына яки урман үрчетү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кискәннән соң бер еллдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урман үрчетү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырганда.

## 2.15. Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану агач материалыннан эшләнмәләр һәм мондый эшкәртүдән бүтән продукция җитештерүгә бәйле булган эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2014 елның 1 декабрендәге 528 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләре белән регламентлана.

Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлекләре гражданнарга, юридик затларга агач материалын һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртү өчен арендага бирелә.

Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе бер елдан башлап кырык тугыз елга кадәрле срокка төзелә.

Әгәр федераль законнарда агач материалын һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртүне федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашыру рөхсәт ителсә, урман кишәрлекләре әлеге учреждениеләргә күрсәтелгән максатка даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылырга мөмкин.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында, барыннан да элек, урмансыз җирләр, ә урман кишәрлегендә андый җирләр булмаганда – кисүләрдән соң торгызылмаган кишәрлекләр, янгыннан калган җирләр, бушлыклар, ачык урыннар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман утыртмалары үсә торган җирләр файдаланыла.

Бүтән урман кишәрлекләреннән күрсәтелгән максатларда файдалану күрсәтелгән объектларны урнаштыруның башка вариантлары булмаганда рөхсәт ителә.

Яклаучы урманнарда урман эшкәртү инфраструктурасын оештыру тыела.

Урманнарны агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен файдаланганда түбәндәге очраклар булдырылмаска тиеш:

урманнарны пычрату (шул исәптән радиоактив матдәләр белән) һәм урманнарга башка төрле тискәре йогынты ясау;

Россия Федерациясе Урман кодексының 53.5 статьясы нигезендә урманнарда урман куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында транспорт чаралары белән үтеп керү.

Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге кишәрлек урманчылыклары буенча әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны торгызуны һәм урман үрчетүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урман торгызу проектына яки урман үрчетү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кискәннән соң бер елдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урман үрчетү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырганда.

## 2.16. Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнар дини оешмалар тарафыннан «Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдаланылырга мөмкин.

Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйриячелек билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне торгызу рөхсәт ителә. Дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә булган урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен түләүсез нигездә файдалануга тапшырыла (Россия Федерациясе Урман кодексының 47 статьясы).

Кишәрлек урманчылыклары буенча дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

## 2.17. Урманнарны саклауга, яклауга һәм яңадан үстерүгә карата таләпләр

### 2.17.1. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләр белән пычранудан һәм тискәре башка йогынтыдан саклауга карата таләпләр

Россия Федерациясе Конституциясенең 9 статьясы һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 51 статьясы нигезендә урманнар янгыннардан сакланырга тиеш.

Урманнарны янгыннардан саклау Россия Федерациясе Урман кодексы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә биологик, урманчылык, экологик һәм төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла һәм урманнардагы янгыннарны булдырмый калуга, вакытында ачыклауга һәм сүндерүгә юнәлдерелгән оештыру, хокукый һәм багка чаралар комплексын үз эченә ала.

Урманнардан файдаланганда, аларны саклаганда, яклаганда, торгызганда, урманнарда бүтән төрле эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, шулай ук урманнарда гражданнар йөргәндә урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча бердәм таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 30 июнендәге 417 номерлы карары белән расланган Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрендә билгеләнгән. Урманнарда янгыннарны кисәтү һәм сүндерү чараларының төрләре, әлеге чаралар белән урманнардан файдаланучы затларны тәэмин итү нормативлары, урманнардан файдаланганда урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының булу нормалары Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2014 елның 28 мартындагы 161 номерлы боерыгында расланган. Урманнарның табигый янгын куркынычлылыгы классификациясе, һава шартларына бәйле рәвештә урманнарда янгын куркынычы классификациясе 2011 елның 5 июлендәге 287 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган.

Урманнарны янгыннардан саклау нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Россия Урман хуҗалыгы федераль агентлыгының 1997 елның 19 декабрендәге 167 номерлы боерыгы белән Янгын-химия станцияләре турында нигезләмә расланды.

Урманчылык мәйданының янгын куркынычы классларына бүленеше киләсе таблицада күрсәтелде.

мәйданы, га

| Номеры | Кишәрлек урманчылыгы | Янгын чыгу куркынычы классы | | | | | Җәмгысе | Уртача класс |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV | V | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | 2523 | 4219 | 4938 | 1286 | - | 12966 | 2,4 |
| Урманчылык буенча барлыгы | | 2523 | 4219 | 4938 | 1286 | - | 12966 | 2,4 |
| % | | 19 | 33 | 38 | 10 | – | 100 | |

Урманда янгын барлыкка килү һәм таралу ихтималы, шулай ук аның интенсивлыгы һава шартларына карап билгеләнә. Бу вакытта метеорологик шартлар арасында янучан материалларны дымландыру яки корыту процессларына бәйлесе

зуррак әһәмияткә ия булып тора. Мондый факторларга түбәндәгеләр керә: явым-төшемнәр, һава дымлылыгы һәм температурасы, җил һәм болытлылык.

Янгын чыгу куркынычының уртача классы тулаем алганда 2,4 тәшкил итә.

Төп мәйданын (38%) 3 нче класслы янгын хәтәренә ия булган урман үсентеләре тәшкил итә.

Урманнарда һава торышына карап, янгын чыгу хәтәрлеге буенча федераль класслар

| Урманнардагы янгын чыгу буенча хәтәрлек классы | Комплекслы күрсәткеч зурлыгы | Янгын чыгуга бәйле хәтәрлек дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I | 0 … 300 | Юк |
| II | 301 … 1000 | Аз |
| III | 1001 … 4000 | Уртача |
| IV | 4001 … 10000 | югары |
| V | 10 000 артык | Гадәттән тыш |

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны янгынга каршы кору чаралары турында» 2011 елның 16 апрелендәге 281 номерлы карарына, «Урманнарны янгынга каршы кору нормативлары раслау турында» 2012 елның 27 апрелендәге 174 номерлы боерыгына таянып, регламентта табигый һәм икътисадый шартларны, урманнарның пирологик сыйфатламаларын, янгынның потенциаль чыганакларын исәпкә алып, янгынга каршы чаралар комплексы билгеләнде.

Янгынга каршы кору чараларының ел саен башкарыла торган күләме киләсе таблицада күрсәтелде.

Янгынга каршы кору буенча чаралар күләме

| т/с | Чараларның аталышы | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Ревизия чорына | 1 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Кисәтү чаралары | | | |
| 1.1. | Даими күргәзмәләр һәм витриналар | данә | 1 | 1 |
| 1.2. | Даими стендлар | данә | 1 | 1 |
| 1.3. | Кисәтүче аншлаглар | данә | 30 | 3 |
| 1.4. | Зарурлыкка карап, даими рәвештә авыл хуҗалыгы формированиеләре вәкилләре белән киңәшмәләр | данә | 10 | 1 |
| 1.5. | Контроль постлар оештыру | данә | 4 | 4 |
| 1.6. | Массакүләм ял итү зоналарында аншлаглар урнаштыру | данә | 2 | 1 |
| 1.7. | Таблосы алмашына торган аншлаглар урнаштыру | данә | 2 | 1 |
| 1.8. | Янгын куркынычы чоры алдыннан матбугатта һәм | лекцияләр | 10 | 1 |

| т/с | Чараларның аталышы | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Ревизия чорына | 1 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | радиода чыгышлар ясау | | | |
| 1.9. | Ял итү һәм тәмәке тарту урыннарын оештыру | данә | 10 | 1 |
| 2. | Янгыннар таралуны чикләү чаралары | | | |
| 2.1. | Янгынга каршы киртәләр, чокырлар ясау | км | - | - |
| 2.2. | Культуралар, ылыслы яшь агачлар тирәли минераллаштырылган полосалар ясау | км | 50 | 5 |
| 2.3. | Ызаннар, юллар буйлап һәм урман поселоклары тирәли минераллаштырылган полосалар ясау | км | 50 | 5 |
| 2.4. | Янгынга каршы аралыкларны карап тоту | км | - | - |
| 2.5. | Минераллаштырылган полосаларны карау | км | 400 | 40 |
| 3. | Юллар төзелеше | | | |
| 3.1. | Я/каршы билгеләнгән юллар төзү | км | 5 | 0,5 |
| 3.2. | Күперләр төзү | данә | 1 | - |
| 3.3. | Янгынга каршы билгеләнештәге юлларны ремонтлау | км | 20 | 2 |
| 3.4. | Урман юллары төзү | км | 5 | 0,5 |
| 4. | Элемтә оештыру | | | |
| 4.1. | Элемтә линияләре төзү | км | - | - |
| 4.2. | Радиостанцияләр (кәрәзле элемтә) сатып алу | данә | 5 | 1 |
| 5. | Дозор-сак хезмәте | | | |
| 5.1. | Вакытлы янгын сакчыларын яллау | кеше | 2 | 2 |
| 6. | Янгыннарга каршы көрәш чаралары | | | |
| 6.1. | 2 типлы янгын-химия станцияләрен карап тоту | данә | 1 | 1 |
| 6.2. | Янгын инвентарьлары пунктларын оештыру | данә | 3 | 3 |
| 6.3. | Ясалма сулыклар төзү | данә | - | - |
| 6.4. | Сулыкларга килә торган юллар (пирслар) ясау | данә | 3 | 3 |
| 6.5. | Ирекле янгын сүндерүче дружиналар оештыру | саны/кеше | 2/12 | 2/12 |
| 7. | Янгынга каршы җайланмалар сатып алу | | | |
| 7.1. | Автомашина ГАЗ-66, УАЗ-469 | данә | 1 | 1 |
| 7.2. | Капрон янгын җиңсәләре | пог. м | 2000 | 200 |
| 7.3. | Мотопомпалар | данә | 1 | 1 |
| 7.4. | Бензопычкылар | данә | 2 | 2 |
| 8. | Янгын куркынычын мониторинглау (ел саен) | мең га | 13,0 | 13,0 |
| 9. | Ел саен урманнарны янгыннардан саклау буенча планлаштырылган чараларга чыгымнар күләме – | мең сум | Республика буенча тулаем каралган | |

| т/с | Чараларның аталышы | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Ревизия чорына | 1 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | барлыгы | | | |
| | шул исәптән: | | | |
| | – Урман янгыннарын сүндерү буенча системалар һәм чаралар булдыру (ПНВ, радио-телефон элемтәсен, моторлы транспортны карап тоту, янгын сакчылары яллау) | мең сум | -//- | |
| | – Урман янгыннарын сүндерү | мең сум | -//- | |
| | – Авиапатруль | мең сум | -//- | |
| | – Башка төрле чаралар (ш.и. янгынга каршы пропаганда) | мең сум | -//- | |

Урманнарда янгынга каршы профилактика уздыруда урман янгыннарына каршы пропаганда әһәмиятле роль уйный, ул урманнарны саклау һәм урман янгыннарын булдырмый калуга җаваплылык рухында җәмәгатьчелек фикерен һәм аерым кешеләрнең карашларын формалаштыру максатында аңга планлы рәвештә йогынты ясауга юнәлдерелгән мәгълүмат-пропаганда чаралары һәм гамәлләре җыелмасыннан гыйбарәт. Урман янгыннарына каршы пропаганда максатчан, оператив булырга, ел чорына, урманнарда халыкның конкрет төркеме тарафыннан башкарыла торган эшчәнлекнең (ял итү, агач әзерләү, экспедицияләр һ.б.) торышына һәм холкына туры килергә, конкрет фактларны үз эченә алырга тиеш, ә басма матбугат чаралары эчтәлекле, кызыклы һәм образлы булырга тиеш.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 17 маендагы 377 номерлы карары белән расланган Урманнардагы янгыннарны сүндерү планын һәм аның формасын эшләү һәм раслау кагыйдәләре нигезендә ел саен Урманнардагы янгыннарны сүндерү планы раслана.

## 2.17.2. Урманнарны яклауга карата таләпләр (санитар-савыктыру чараларының, урманнарны яклау буенча профилактика чараларының, зарарлы организмнарның чыганакларын ликвидацияләү чараларының, шулай ук вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән башка чараларның нормативлары һәм параметрлары)

Урманнарны яклау урманнарда зарарлы организмнарны ачыклауга һәм аларның таралуын кисәтүгә, ә зарарлы организм чыганаклары барлыкка килгән очракта, аларны бетерүгә юнәлдерелгән.

Урманнарны яклау дәүләт хакимияте органнары тарафыннан аларның Россия Федерациясе Урман кодексының 81-84 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны зарарлы организмнардан яклау Россия Федерациясе Урман кодексының 60.1-60.10 статьялары һәм «Үсемлекләр карантины турында» 2014 елның 21 июлендәге 206-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 20 маендагы 607 номерлы карары белән расланган Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнардагы санитар куркынычсызлык чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала: урман яклау районнарына бүлү, дәүләт урман-патологик мониторингы, урман патологиясе буенча тикшеренүләр уздыру, зарарлы организмнар таралуын кисәтү, урманнарда санитар куркынычсызлык буенча башка чаралар.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан урман фонды җирләрендә урманнарны яклау районнарына бүлү «Рослесозащита» ФБУ филиалы – «Татарстан Республикасы Урман яклау үзәге» тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Урманнарны яклау районнарына бүлү тәртибе Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы белән расланган.

Урман патологиясе буенча дәүләт мониторигын уздыру тәртибе шулай ук «Рослесозащита» ФБУ филиалы – «Татарстан Республикасы Урман яклау үзәге» тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Урман патологиясе буенча дәүләт мониторигын уздыру тәртибе Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 5 апрелендәге 156 номерлы боерыгы белән расланган.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләр (алга таба – УПТ) урманнарда дәүләт урман-патологик мониторинг белешмәләрен, шулай ук урманнарның санитар һәм урман-патологик торышы турында башка мәгълүматларны исәпкә алып уздырыла.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләрне уздыру тәртибе, урман патологиясе буенча тикшерү актының формасы Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 16 сентябрендәге 480 номерлы боерыгы белән расланган.

УПТ урман кишәрлекләренең агымдагы санитар һәм урман-патологик торышы турында мәгълүмат алу, шулай ук зарарлы организмнар таралуны кисәтү чараларын нигезләү һәм билгеләү максатларында уздырыла.

УПТ материаллары нигезендә санитар-савыктыру чаралары (алга таба – ССЧ) уздырыла.

ССЧ урман утыртмаларының санитар торышын яхшырту, зарарлы организмнар таралу куркынычын киметү, урман утыртмаларының үзләренең максатчан функцияләрен үтәвен тәэмин итү, шулай ук тискәре факторлар йогынтысыннан килгән зыянны киметү максатында Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 12 сентябрендәге 470 номерлы боерыгы белән расланган Зарарлы организмнар таралуын кисәтү чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре нигезендә уздырыла.

Зыянлы организмнарның таралуын кисәтү чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләрендә зыянлы организмнарга каршы көрәш алып бару буенча санитар-савыктыру, профилактикалау һәм агитацияләү чараларын, аларның чиратын һәм

башкару тәртибен үз эченә ала торган урман хуҗалыгы эшләренең комплексы тасвирлана.

Махсус саклanучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнарда зарарлы организмнар таралуын кисәтү чараларын уздыру территорияләрне махсус саклау режимын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисүнең, ликвид булмаган агач материалын, шулай ук аварияле агачларны җыештыруның планлаштырылган күләмнәре 15 нче таблицада китерелде.

15 нче таблица

Санитар-савыктыру чараларының нормативлары һәм параметрлары

| т/с | Күрсәткечләр | Үлч. бер. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Аварияле агачларны җыештыру | Ликвидсыз агачларны җыештыру | Җәмгысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Шул исәптән | | | | |
| | | | | Тоташ | Сайланма | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Урманнарның максатчан билгеләнеше – яклаучы урманнар | | | | | | | | |
| Ылыслы | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – нарат | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 102 | – | 102 | | | 102 |
| | | Мең м3 | 3,7 | – | 3,7 | | | 3,7 |
| Өстенлек итүче токым – чыршы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 147 | 31 | 116 | | | 147 |
| | | Мең м3 | 9,0 | 6,1 | 2,9 | | | 9,0 |
| Өстенлек итүче токым – Пихта | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 13 | 1 | 12 | | | 13 |
| | | мең м3 | 0,7 | 0,1 | 0,6 | | | 0,7 |
| җәмгысе ылыслы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 262 | 32 | 230 | | | 262 |
| | | Мең м3 | 13,4 | 6,2 | 7,2 | | | 13,4 |
| Каты яфраклы | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – югары кәүсәле имән | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | – | 8 | | | 8 |
| | | мең м3 | 0,2 | – | 0,2 | | | 0,2 |
| Өстенлек итүче токым – тәбәнәк кәүсәле имән | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 32 | – | 32 | | | 32 |
| | | Мең м3 | 0,5 | - | 0,5 | | | 0,5 |
| Җәмгысе каты яфраклы | | | | | | | | |

| т/с | Күрсәткечләр | Үлч. бер. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Авари-яле агач-ларны җыеш-тыру | Ликвид-сыз агачлар-ны җыеш-тыру | Җәм-гысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Шул исәптән | | | | |
| | | | | Тоташ | Сай-ланма | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 40 | – | 40 | | | 40 |
| | | Мең м3 | 0,7 | – | 0,7 | | | 0,7 |
| Йомшак яфраклылар | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – каен | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | – | 8 | | | 8 |
| | | мең м3 | 0,2 | – | 0,2 | | | 0,2 |
| Өстенлек итүче токым – усак | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 2 | – | 2 | | | 2 |
| | | мең м3 | 0,1 | – | 0,1 | | | 0,1 |
| Өстенлек итүче токым – Кара зирек | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 3 | – | 3 | | | 3 |
| | | Мең м3 | 0,1 | – | 0,1 | | | 0,1 |
| Өстенлек итүче токым – юкә | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 15 | 5 | 10 | | | 15 |
| | | мең м3 | 1,4 | 1,2 | 0,2 | | | 1,4 |
| Җәмгысе йомшак яфраклы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 28 | 5 | 23 | | | 28 |
| | | Мең м3 | 1,8 | 1,2 | 0,6 | | | 1,8 |
| Яклаучы урманнар буенча җәмгысе | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 330 | 37 | 293 | | | 330 |
| | | Мең м3 | 16,0 | 7,5 | 8,5 | | | 16,0 |
| Урманнарның максатчан билгеләнеше – Эксплуатация урманнары | | | | | | | | |
| Ылыслы | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – нарат | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 81 | 2 | 79 | | 2 | 83 |
| | | Мең м3 | 3,7 | 0,3 | 3,4 | | 0,3 | 4,0 |
| Өстенлек итүче токым – чыршы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 38 | – | 38 | | 2 | 40 |
| | | Мең м3 | 1,1 | – | 1,1 | | 0,3 | 1,4 |
| җәмгысе ылыслы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 119 | 2 | 117 | | 4 | 123 |
| | | Мең м3 | 4,8 | 0,3 | 4,5 | | 0,6 | 5,4 |
| Йомшак яфраклылар | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – каен | | | | | | | | |

| т/с | Күрсәткечләр | Үлч. бер. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Авари-яле агач-ларны җыеш-тыру | Ликвид-сыз агачлар-ны җыеш-тыру | Җәм-гысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Шул исәптән | | | | |
| | | | | Тоташ | Сай-ланма | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 90 | 1 | 89 | | | 90 |
| | | Мең м3 | 3,5 | 0,1 | 3,4 | | | 3,5 |
| Өстенлек итүче токым – Усак | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | – | 8 | | | 8 |
| | | мең м3 | 0,4 | – | 0,4 | | | 0,4 |
| Өстенлек итүче токым – юкә | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 1 | – | 1 | | | 1 |
| | | мең м3 | 0,1 | – | 0,1 | | | 0,1 |
| Җәмгысе йомшак яфраклы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 99 | 1 | 98 | | | 99 |
| | | мең м3 | 4,0 | 0,1 | 3,9 | | | 4,0 |
| эксплуатация урманнары буенча җәмгысе | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 218 | 3 | 215 | | 4 | 222 |
| | | Мең м3 | 8,8 | 0,4 | 8,4 | | 0,6 | 9,4 |
| Урманчылык буенча барлыгы | | | | | | | | |
| Ылыслы | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – нарат | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 183 | 2 | 181 | | 2 | 185 |
| | | Мең м3 | 7,4 | 0,3 | 7,1 | | 0,3 | 7,7 |
| Өстенлек итүче токым – чыршы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 185 | 31 | 154 | | 2 | 187 |
| | | Мең м3 | 10,1 | 6,1 | 4,0 | | 0,3 | 10,4 |
| Өстенлек итүче токым – Пихта | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 13 | 1 | 12 | | | 13 |
| | | мең м3 | 0,7 | 0,1 | 0,6 | | | 0,7 |
| җәмгысе ылыслы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 381 | 34 | 347 | | 4 | 385 |
| | | Мең м3 | 18,2 | 6,5 | 11,7 | | 0,6 | 18,8 |
| Каты яфраклы | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – югары кәүсәле имән | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 8 | – | 8 | | | 8 |
| | | мең м3 | 0,2 | – | 0,2 | | | 0,2 |
| Өстенлек итүче токым – тәбәнәк кәүсәле имән | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре | га | 32 | – | 32 | | | 32 |

| т/с | Күрсәткечләр | Үлч. бер. | Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү | | | Авари-яле агач-ларны җыеш-тыру | Ликвид-сыз агачлар-ны җыеш-тыру | Җәм-гысе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | Шул исәптән | | | | |
| | | | | Тоташ | Сай-ланма | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | буенча ачыкланган фонд | Мең м3 | 0,5 | - | 0,5 | | | 0,5 |
| Җәмгысе каты яфраклы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 40 | – | 40 | | | 40 |
| | | Мең м3 | 0,7 | – | 0,7 | | | 0,7 |
| Йомшак яфраклылар | | | | | | | | |
| Өстенлек итүче токым – каен | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 98 | 1 | 97 | | | 98 |
| | | Мең м3 | 3,7 | 0,1 | 3,6 | | | 3,7 |
| Өстенлек итүче токым – Усак | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 10 | – | 10 | | | 10 |
| | | мең м3 | 0,5 | - | 0,5 | | | 0,5 |
| Өстенлек итүче токым – Кара зирек | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 3 | – | 3 | | | 3 |
| | | Мең м3 | 0,1 | – | 0,1 | | | 0,1 |
| Өстенлек итүче токым – Юкә | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 16 | 5 | 11 | | | 16 |
| | | мең м3 | 1,5 | 1,2 | 0,3 | | | 1,5 |
| Җәмгысе йомшак яфраклы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 127 | 6 | 121 | | | 127 |
| | | Мең м3 | 5,8 | 1,3 | 4,5 | | | 5,8 |
| Барлыгы | | | | | | | | |
| 1 | Урман таләпләре буенча ачыкланган фонд | га | 548 | 40 | 508 | | 4 | 552 |
| | | Мең м3 | 24,7 | 7,9 | 16,8 | | 0,6 | 25,3 |

Искәрмә: Санитар-савыктыру чараларының күләменә урман патологиясе тикшерүләре акты нигезендә үзгәрешләр кертелә («Урманнарны зарарлы организмнардан яклауны җайга салуны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 30 декабрендәге 455 номерлы федераль закон буенча).

Урманны яклау буенча чаралар күләме корткычларның яңа чыганаклары һәм урман авырулары барлыкка килүгә бәйле рәвештә һәм утыртмаларның санитар торышы үзгәрүгә карап үзгәртелергә тиеш.

УПТ нәтиҗәләре профилактика чараларын планлаштыру нигезе булып тора. Профилактика чараларын планлаштыру нәтиҗәләре урман хуҗалыгы регламентларында һәм урманнарны үзләштерү проектларында чагылдырыла.

15.1 нче таблица

Зарарлы организмнар таралуны кисәтү буенча профилактика һәм башка төрле чараларның параметрлары

| Чараның аталышы | Үлчәү берәмлекләре | Чараның күләме | Уздыру чоры | Чараның ел саен башкарыла торган күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1. Профилактик | | | | |
| 1.1. Урман хуҗалыгы | | | | |
| 1. Бер мәртәбәгә исәпләгәндә питомникларга сибү (серкәләндерү) | га | 20 | 10 | 2 |
| 2. Орлыкларны агулау | кг | 50 | 10 | 5 |
| 1.2 Биотехник | | | | |
| 1. Оялыклар әзерләү | данә/мең гектар | 130/130 | 10 | 13/13 |
| 2. Ояларны ремонтлау | данә/мең гектар | 130/130 | 10 | 13/13 |
| 3. Аттрактант тозаклар куллану | данә | 50 | 10 | 5 (зарурлык булуга карап) |
| 4. Кырмыска ояларын киртәләү | данә | 50 | 10 | 5 (кишәрлек урм. буенча 5 данә) |
| 5. Кырмыскалыкларның урынын алмаштыру (күчерү) | оя | 20 | 10 | 2 |
| | | | | |
| 2. Башка чаралар | | | | |
| 1. Яклау почмаклары булдыру һәм карап тоту | данә | 1 | 1 | 1 |
| 2. Корткыч һәм авыру чыганаклары барлыкка килүне күзәтеп тору | мең га | 13,0 | 1 | 13,0 |
| 3. Халык белән, агач әзерләүчеләр белән әңгәмәләр кору, лекцияләр уздыру | әңгәмә | 20 | 10 | 2 |
| 4. Аншлаглар һәм плакатлар урнаштыру һәм элү | данә | 20 | 10 | 2 |

15.2 нче таблица

Зарарлы организмнарның чыганакларын юкка чыгару чараларының параметрлары

| Чараның аталышы | Үлчәү берәмлекләре | Чараның күләме | Уздыру чоры | Чараның ел саен башкарыла торган күләме |
|---|---|---|---|---|
| Урман патологиясе ягыннан тикшерү | га | 1000 | 10 | 100 |
| Көрәшнең җир өсте чаралары | га | зарарлану чыганаклары барлыкка килүгә карап | | |
| Туфрак казулар | чокыр | 300 | 10 | 30 |

## 2.17.3. Урманнарны яңадан үстерүгә карата таләпләр

Киселгән, һәлак булган, зарар күргән урманнар торгызылырга тиешле.

Россия Федерациясе Урман кодексының 61 статьясының 2 п. нигезендә урманнарны торгызу түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) урман орлыкчылыгы;
2) урман торгызу;
3) урманнарны тәрбия кылу;
4) урман торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары били торган җирләргә кертү.

Урман орлыкчылыгы «Орлыкчылык турында» 1997 елның 17 декабрендәге 149-ФЗ номерлы федераль законга һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 65 статясына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны торгызу Россия Федерациясе Урман кодексының 61, 62 статьялары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның 25 мартындагы 188 номерлы боерыгы белән расланган Урманнарны торгызу кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны торгызу кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны үрчетү Россия Федерациясе Урман кодексының 63 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2018 елның 28 декабрендәге 700 номерлы боерыгы белән расланган Урманнарны үрчетү кагыйдәләре (алга таба – Урманнарны үрчетү кагыйдәләре) нигезендә башкарыла.

Урманнарны тәрбия кылу Россия Федерациясе Урман кодексының 64 статьясына, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 ноябрендәге 626 номерлы боерыгына (алга таба – Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләре) ярашлы рәвештә регламентлана.

Урманнарны тәрбия кылу эшләре урманнарны урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе, урман кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукы яки урман кишәрлегеннән түләүсез нигездә файдалану хокукы нигезендә файдаланучы затлар тарафыннан яки дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренең Россия Федерациясе Урман кодексының 81-84 статьяларында, Россия Федерациясе Урман кодексының 19 статьясында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә (алга таба – дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары) гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урманнарны тәрбия кылу эшләре Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләренә туры китереп, чара төрләре буенча Россия Федерациясе субъектларының урман планнарында, урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларында, урманнарны үзләштерү проектларында күрсәтелгән күләмнәрдә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны карап тоту чараларына урман утыртмаларын тәрбия кылу максатларында уздырыла торган кисүләр; агроурман-меолиоратив чаралар; бүтән чаралар, шул исәптән урман утыртмаларын яңарту; урман утыртмаларының формасын үзгәртү; урман утыртмаларын реконструкцияләү; урманнарны урманчылык-урман яклау буенча тәрбияләү; урманның яңарышын, шытымнарын һәм утыртмаларның башка кыйммәтле компонентларын (тәрбия объектларын) карау; урманнарны рекреацион-ландшафт тәрбияләү; урманнарны тәрбия кылуның ярдәмче төрләре; урманнарны карауның махсус төрләре керә.

Урманнарны карау чаралары эксплуатация урманнарының максатчан билгеләнешен, яклаучы урманнарның һәм махсус якланучы урман кишәрлекләренең категорияләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Эксплуатация урманнарында урманнарны тәрбия кылу чаралары урманнарның продуктлылыгын арттыруга, югары сыйфатлы агач материалы һәм агач булмаган урман ресурслары алуга юнәлдерелгән.

Эксплуатация урманнарында ясалма һәм табигый барлыкка килгән, агач материалына ихтыяҗ зур булган максатчан агач токымнарына карата тәрбияви чаралар башкарыла. Максатчан агач токымнары Россия Федерациясе субъектының урман планында агач материалын җитештерү структурасына һәм аңа булган ихтыяҗга ясалган анализ нигезендә билгеләнергә тиеш.

Яклаучы урманнарда һәм махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урманнарны карау чаралары тирәлек урманнарның хасил итүче, су саклаучы, яклаучы, санитар-гигиена, савыктыру һәм файдалы функцияләрен саклауга һәм торгызуга юнәлдерелгән.

Яклаучы урманнар һәм урманнарның махсус якланучы кишәрлекләре өчен максатчан токымлы агачлар булып яклаучы урманнарның һәм махсус яклана торган урман кишәрлекләренең максатчан билгеләнешенә җавап бирә торган агач токымнары санала.

Урманнарны карау буенча уздырылган чараларның сыйфатлылыгын һәм нәтиҗәлелеген бәяләү дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 27 июнендәге 367 номерлы боерыгы белән расланган Диләнкеләрне карау тәртибенә туры китереп, диләнке эшләре тәмамланганнан соң диләнкеләрне караганда, Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Дәүләт урман реестрына документлаштырылган мәгълүматларны кертүгә һәм аны үзгәртүгә нигез булган документларның исемлеген, формасын һәм аларны әзерләү тәртибен раслау турында» 2013 елныд 11 ноябрендәге 496 номерлы боерыгы белән расланган тәртиптә дәүләт урман реестрына мәгълүмат керткәндә һәм аны үзгәрткәндә гамәлгә ашырыла.

Урман торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары биләгән җирләргә кертү Россия Федерациясе Урман кодексының 64.1 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман утыртмалары вәкаләтле федераль башкарма хакимияте билгеләгән критерияләргә һәм таләпләргә җавап биргән очракта, урман торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары били торган җирләргә кертү дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның Россия Федерациясе Урман кодексының 81-84 статьяларына ярашлы рәвештә билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Урман торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары били торган җирләргә кертү тәртибе һәм тиешле акт формасы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

Яшь агачларны карау һәм урманнарны карау буенча тәрбия кылуга бәйле булмаган бүтән чараларның нормативлары һәм параметрлары 16 нчы таблицада китерелде.

16 нчы таблица

Яшь агачларны карау һәм урманнарны карау буенча тәрбия кылуга бәйле булмаган бүтән чараларның нормативлары һәм параметрлары

| Урманнарны тәрбия кылу төрләре аталышы | Кишәрлек урманчылы-гының атылышы | Хуҗалык | Агач токымы | Мәй-даны, га | Киселә торган запас, $м^3$ | Кабат-лану чоры, ел | Еллык күләме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | мәйданы, га | киселә торган запас, куб.м | |
| | | | | | | | | гомуми | 1 гектардан |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Яшь агачлар арасында урманнарны карау буенча кисүләр уздыру | | | | 775 | 10080 | | 105 | 1266 | 13 |
| шул исәптән | | | | | | | | | |
| тоныкландырулар | Кишәрлек урманчылыкла рына бүлмичә | Ылысклы | Нарат | 77 | 450 | 3-5 | 15 | 90 | 6 |
| | | -//- | Чыршы | 171 | 1070 | 4-6 | 28 | 178 | 6 |
| | | җәмгысе ылыслы | | 248 | 1520 | | 43 | 268 | 6 |
| | | Каты яфраклы | Б/кәүс. имән | 5 | 30 | | 1 | 6 | 6 |
| Урманчылык буенча җәмгысе тоныкландырулар | | | | 253 | 1550 | | 44 | 274 | 6 |
| тазартулар | Кишәрлек урманчылыкла рына бүлмичә | Ылыслы | Нарат | 163 | 2980 | 8-12 | 16 | 298 | 18 |
| | | -//- | Чыршы | 359 | 5550 | 8-10 | 45 | 694 | 15 |
| | | җәмгысе ылыслы | | 522 | 8530 | | 61 | 992 | 16 |
| Урманчылык буенча җәмгысе тазартулар | | | | 522 | 8530 | | 61 | 992 | 16 |
| Агло-урман-орлык-мелиоратив чаралар уздыру юлы белән урманнарны карау | Кишәрлек урманчылыкла рына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Урманнарны карау буенча башка чаралар, шул исәптән: | | | | | | | | | |
| аз кыйммәтле урман утыртмаларын реконструкцияләү | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |
| агач токымнарының җимеш бирүен карау | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |
| агач ботакларын кискәләү | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | | | | - | - | - |
| урманнарны ашлау | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | | | | - | - | - |
| урман кырыйларын карау | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |
| чыбылдыкны карау | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |
| урманнарны кирәксез урман үсемлекләрен юкка чыгару юлы белән карау | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |
| башка чаралар | Кишәрлек урманчылыкларына бүлмичә | - | - | - | - | - | - | - | - |

Урман үскән шартларның типларын, бонитет классларын, караганчыга кадәр составы буенча утыртмаларның төркемен, чыбылдыкның караганнан соңгы минималь йомыклыгын, агачлар саны яисә массасы буенча сайлау процентын күрсәтеп, өстенлек итүче һәр токым буенча тәрбияви кисү режимының нормативлары Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләрендә билгеләнгән.

1. Кисүләрнең максималь ешлык проценты тоташлыгы (тулылыгы) 1,0 тигез булган утыртмалар өчен китерелде. Тоташлыкның (тулылыкның) түбәнрәк күрсәткечләрендә, кисәк тотрыклылык киму куркынычы янаганда һәм башка начар шартларда, шулай ук техник коридор челтәрле кишәрлекләрен тәрбия кылганда кисүләрнең ешлыгы, әлбәттә, кими.

2. Технологик коридорларны (запасы буенча 5-7%ка) кисеп чыкканда һәм кирәкмәгән агачларны күп күләмдә юк итү зарурлыгы булганда ешлыкны арттыру рөхсәт ителергә мөмкин.

Урман торгызу һәм урман үрчетү буенча чаралар үткәрү таләп ителгән мәйданнарның зурлыклары 17 нче таблицада күрсәтелде.

17 нче таблица

Урман торгызу һәм урман үрчетү буенча чараларның нормативлары һәм параметрлары

мәйданы, га

| Күрсәткечләр | Урман үсемлекләре капламаган җирләр | | | | Алдагы чорда тоташ кисү диләнкеләре | Урман үрчетү | Барлыгы | Еллык күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Көекләр һәм һәлак булган утыртмалар | Киселгән урыннар | Аланлыклар һәм буш урыннар | Җәмгысе | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Урман торгызуга мохтаҗ урыннар, барлыгы | 4 | 99 | 6 | 109 | 718 | - | 827 | 83 |
| шул исәптән яшь төркемнәре буенча | | | | | | | | |
| Ылыслы | 4 | 64 | 5 | 73 | 142 | - | 215 | 22 |
| Каты яфраклы | – | – | 1 | 1 | - | – | 1 | - |
| Йомшак яфраклылар | – | 35 | – | 35 | 576 | - | 611 | 61 |
| шул исәптән түбәндәге урман торгызу ысуллар буенча | | | | | | | | |
| ясалма (урман культуралары булдыру), барлыгы | 4 | 63 | 6 | 73 | 261 | - | 334 | 33 |
| Шулардан төркемнәр буенча<br>Токым | | | | | | | | |

| Күрсәткечләр | Урман үсемлекләре капламаган җирләр | | | | Алдагы чорда тоташ кисү диләнкеләре | Урман үрчетү | Барлыгы | Еллык күләме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Көекләр һәм һәлак булган утыртмалар | Киселгән урыннар | Аланлыклар һәм буш урыннар | Җәмгысе | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Ылыслы | 4 | 63 | 5 | 72 | 245 | - | 317 | 31 |
| Каты яфраклы | – | – | 1 | 1 | 16 | - | 17 | 2 |
| Йомшак яфраклылар | – | - | - | - | - | - | - | - |
| табигый урман торгызу, барлыгы | – | 36 | – | 36 | 457 | | 493 | 50 |
| алардан токым төркемнәре буенча: | | | | | | | | |
| Ылыслы | – | 1 | – | 1 | 67 | – | 68 | 7 |
| Йомшак яфраклылар | – | 35 | – | 35 | 390 | - | 425 | 43 |
| шул исәптән | | | | | | | | |
| шытым саклау | – | - | - | – | 67 | – | 67 | 7 |
| шулардан төркемнәр буенча Токым | | | | | | | | |
| Ылыслы | – | - | - | – | 67 | – | 67 | 7 |
| табигый урман торгызу, барлыгы | – | 36 | – | 36 | 390 | - | 426 | 43 |
| Шулардан төркемнәр буенча Токым | | | | | | | | |
| Ылыслы | – | 1 | – | 1 | - | – | 1 | - |
| Йомшак яфраклылар | – | 35 | – | 35 | 390 | - | 425 | 43 |
| Урман үрчетүгә мохтаҗ җирләр | – | - | - | - | - | - | - | – |

Искәрмә: Тоташ кисүләр буенча ел саен файдалануга рөхсәт ителә торган диләнке күләме үзләштерелмәгән очракта, урман торгызу эшләренең күләме үзгәртелергә мөмкин.

Урман культураларын булдыру технологиясе туфрак-типологик шартларга бәйле. Технология нигезе сыйфатында Урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру буенча россиякүләм фәнни-тикшеренү институтында урман торгызу буенча эшләнгән хисапнамә-технологик карталар киңәш ителә.

Урман агач токымнарының утырту материалына һәм урманнарны ясалма һәм катнаш торгызганда булдырылган, мәйданнары урман үсемлекләре белән капланган җирләргә кертелә торган яшь агачлар сыйфатына карата белдерелә торган криетрияләр һәм таләпләр Урман торгызу кагыйдәләре белән регламентлана.

## 2.18. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясе Урманлы районнар исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы нигезендә Урманчылыкның барча территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасының ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районында урнашкан.

Урман хуҗалыгы регламентында китерелгән нормативлар Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнар зонасының ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районына туры килә.

# 3 БҮЛЕК. Урманнардан файдалануда чикләмәләр

## 3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләмәләр

Урманнарны максатчан билгеләнеш төрләре һәм яклаучы урман категорияләре буенча чикләүләр 18 нче таблицада китерелде.

18 нче таблица

Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләмәләр

| т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Яклагыч урманнар | Яклагыч урманнарда тоташ кисүләрне уздыру әлеге Кодексның 21 статьясының 5.1 өлешендә каралган очракларда һәм сайланма кисүләр үзләренең тиргәлек хасил итә, су саклый торган, санитар-гигиеник, савыктыру һәм башка төрле функцияләрен югалта башлаган урман утыртмаларын яклагыч урманнарның максатчан билгеләнешен һәм алар башкара торган файдалы вазыйфаларны саклауны тәэмин итә торган урман утыртмаларына алмаштыруны тәэмин итмәгән очракларда гамәлгә ашырыла, әгәр әлеге Кодекста башкача билгеләнмәсә. |
| 2. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>3) урман плантацияләре төзү һәм алардан файдалану;<br>4) линияле объектлардан, гидротехник корылмалардан һәм нефть һәм табигый газ табу, эзләү һәм чыгару өчен кирәкле объектлардан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану. |
| 3. | Табигый һәм башка төр объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнар<br>а) яклагыч урман полосаларында урнашкан урманнар (тимер юл транспорты турында Россия Федерациясе законнары, автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында законнар нигезендә билгеләнгән тимер юлларга бүлеп бирелгән полосалар чикләрендә һәм автомобиль юлларының юл буе полосаларында урнашкан урманнар)<br>б) урман паркы зоналарында урнашкан урманнар (урман фонды | Тыела:<br>1) техник регламентта каралганнан киңрәк итеп линияле корылмалар кисү;<br>2) урман түшәмәсен белән мүк җыю һәм әзерләү.<br>Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>5) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш;<br>Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен |

| т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | җирләрендә һәм халыкның ялын оештыру, санитария-гигиена, савыктыру функцияләрен һәм табигый ландшафтларның эстетик кыйммәтен саклау максатларында кулланыла торган башка категория җирләрендә урнашкан урманнар)<br>в) яшел зоналарда урнашкан урманнар (халыкны табигый һәм техноген чыгышның тискәре күренешләре йогынтысыннан яклауны тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм торгызу максатларында бүлеп бирелә торган урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә урнашкан урманнар) | гамәлгә ашыру;<br>3) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>4) авыл хуҗалыгын алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында коймалар кую;<br>5) капиталь төзелеш объектлары төзү һәм алардан файдалану, гидротехника корылмаларыннан, элемтә линияләреннән, электрүткәргеч линияләрдән, җир асты торбаүткәргечләреннән гайре; |
| 4. | Кыйммәтле урманнар | Линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану тыела.<br>Су объектлары буйларында урнашкан яклагыч урман полосаларында линияле объектлардан, гидротехника корылмаларыннан һәм нефть һәм табигый газ табу, эзләү һәм чыгару өчен кирәкле объектлардан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану тыела.<br>Чикләвекле-кәсепчелек зоналарында урнашкан урманнарда агач материалы әзерләү тыела. |
| 5. | Эксплуатация урманнары | Урманнардан файдалануның барлык төрләре дә рөхсәт ителә. |

## 3.2. Махсус якланучы урман кишәрлеге төрләре буенча чикләмәләр

Махсус якланыла торган урман кишәрлекләренең хокукый режимы Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясы. Махсус якланучы урман кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнеше белән файдалы үзлекләренә ярашмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыру тыела.

Махсус якланучы урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләмәләр 19 нчы таблицада күрсәтелде.

19 нчы таблица

Махсус якланучы урман кишәрлеге төрләре буенча чикләмәләр

| т/с | Махсус якланучы урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |

| т/с | Махсус якланучы урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су объектлары, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч, туфраксаклагыч урман кишәрлекләре | Махсус якланыла торган урман кишәрлекләрендә, РФ Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш, түбәндәгеләр тыела:<br>1) әлеге Кодексының 17 статьясының 4 өлешендә, 21 статьясының 5.1 өлешендә каралган очраклардан тыш, урман утыртмаларына тоташ кисүләр үткәрү;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>3) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш.<br>3. Махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә сайланма кисүләр уздыру фәкать һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү максатларында гына уздырыла. |
| 2. | Урмансыз киңлекләр белән чиктәш булып торучы урман кырыйлары | |
| 3. | Урман-орлык плантацияләре, даими урман-орлык кишәрлекләре һәм урман орлыкчылыгының башка объектлары | |
| 4. | Реликт һәм эндемик үсемлекләре булган урман кишәрлекләре | |
| 5. | Сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең яшәү урыннары | |
| 6. | Махсус якланучы башка урман кишәрлекләре | |
| 7. | Тыюлыклы урман кишәрлекләре | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>1) урман утыртмаларын кисү;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратлары куллану;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшкәртү;<br>5) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру |

Искәрмә: Махсус якланучы урман кишәрлекләре урнашкан җир һәм аларның мәйданы урманнар коруны проектлаганда күрсәтелә.

## 3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр

Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр түбәндәге таблицада китерелде.

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Агач әзерләү | Файдалану өчен исәпкә алынган диләнкене (агач материалы алуның мөмкин булган күләменнән) артып китә торган күләмдә, шулай ук кисентеләрнең яшен бозып, агач материалы әзерләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 29 статьясының 4 өлеше). Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 13 сентябрендәге 474 номерлы боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү кагыйдәләре нигезендә: |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;<br>б) диләнкедән читтә урман утыртмаларын, үсемчелек катламын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка төрле калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;<br>в) юлларны, күперләрне һәм ызаннарны, шулай ук киптерүче челтәрне, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агымнарын, чишмәләрне, елгаларны саклау мөһим;<br>г) аударылыган һәм асылынып төшкән, киселгән агачларны (киселгән һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) калдыру, сакланырга тиешле яшь шытымны зарарлау яисә һәлак итү тыела;<br>д) чик, квартал, диләнке баганаларын һәм башкаларын, агачларда һәм түмәрләрдәге тамгаларны, ярлыкларны һәм саннарны бетерү яисә зарарлау тыела;<br>е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Агач материалы әзерләү кагыйдәләре һәм урман законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык бирү чыганакларын һәм плюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;<br>ж) рөхсәт ителгән вакыты (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) тәмамлангач үзагач әзерләү, шулай ук файдалану хокукы туктатылгач яисә тәмамлангач үзагач әзерләү рөхсәт ителми;<br>з) билгеләнгән вакытына (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) алып чыгылмаган агач материалын диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;<br>и) диләнке ясауның технологик картасында каралмаган урыннарга агач материалы чыгару, тарттыру рөхсәт ителми;<br>к) диләнке чистарту эшләрен үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;<br>л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала, туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми.<br>Диләнкеләрдә үзагач әзерләгәндә яшәргә яраклы, аларның табигый ареалы чикләрендә үсеп китүче (әгәр дә тиешле агач токымының урманнар составындагы мәйданы өлеше урманчылык мәйданының 1 процентыннан артып китмәсә) кыйммәтле агач токымнарын (имән, бук, корычагач, эрбет, юкә, күг, элмә, кара зирек, чәчә торган каштан) кисү рөхсәт ителми.<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән зат төрләре сакланырга тиешле.<br>Агач материалы әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында өч һәм аннан да күбрәк берәмлектә эрбет булган, өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланууда чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | Түбәндәгеләргә кирт салу тыела:<br>а) юкка чыгарганчыга кадәр зарарлы организм чыганакларында урнашкан урман утыртмаларына;<br>б) урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;<br>в) Россия Федерациясе законнары нигезендә үзагач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына;<br>г) даими урман-орлык кишәрлекләрендә, урман-орлык плантацияләрендә, генетика резервацияләрендә урнашкан урман утыртмаларына, шулай ук плюс агачларына, орлыклыкларга, орлык чәчәклекләренә һәм полосаларына (2012 елның 24 гыйнварындагы 23 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләренең 7 пункты). |
| 3. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен үсемлекләрнең түбәндәге төрләрен куллану тыела:<br>– Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;<br>– наркотик матдәләр дип танылучыларны;<br>– агачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгәннәрне.<br>Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу чикләнергә яки радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә тыелырга мөмкин. 2011 елның 2018 елның 16 июлендәге 325 номерлы боерык Россия Табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән расланган Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу кагыйдәләре нигезендә:<br>– эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары, чокыр авышлыклары буйларында урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, шулай ук тулылыгы 0,8-1,0 тигез булган яшь агачларда һәм йомылмаган урман культураларында түмәр сагызын әзерләү рөхсәт ителми (13 пункт);<br>– агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела (14 пункт);<br>– урманнарда табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урман түшәмәләрен җыярга рөхсәт ителми (20 пункт). |
| 4. | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | Төрләре Кызыл китапка, Татарстан Республикасы кызыл китабына кертелгән яки наркотик матдәләр булып саналган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителми.<br>Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу радиоактив матдәләр белән пычранган |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин.<br>2011 елның 5 декабрендәге 511 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу кагыйдәләре нигезендә:<br>– җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешләр әзерләү өчен ботакларны кискәләү тыела (14 пункт);<br>– чикләвекләрне әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, шулай ук агачларга һәм куакларга зыян сала торган ысулларны куллану тыела (15 пункт);<br>– гөмбәләр әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш (16 пункт);<br>– каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә кимендә 5 ел калгач рөхсәт ителә (17 пункт);<br>– башка төрле азык-төлек ресурслары әзерләү аларның үсентеләре торышына зыян салмый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш; үсемлекләрне тамырлары белән өзеп алырга, яфракларына (ботакларына) һәм тамырларына зыян салырга рөхсәт ителми (18 пункт). |
| 5. | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру | Яшел зоналарда урнашкан һәм урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда, шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешенең 2 пункты). |
| 6. | Авыл хуҗалыгы алып бару | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 113 статьясының 2 пункты).<br>Яклаучы урманнарның яр буе чикләрендәге җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру тыела (Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясының 17 өлешендәге 1, 3 пунктлары).<br>Урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 3 пункты).<br>Яшел зоналарда урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында киртәләп алулардан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 4 өлешендәге 2 пункты).<br>Махсус яклаһыла торган урман кишәрлекләрендә, печән чабудан һәм умартачылыктан кала, авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясының 4 өлешенең 2 пункты). |
| 7. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудa чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату (2011 елның 23 декабрендәге 548 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләренең 9 пункты).<br>Агулы химик препаратларны куллану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 112 статьясының 4 өлеше, 113 статьясының 1 өлеше, 114 статьясының 2 өлешнең 1 пункты, 4 өлешенең 1 пункты). |
| 8. | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиеш (Россия Федерациясе Урман кодексының 41 статьясының 3 өлеше).<br>2012 елның 21 февралендәге 62 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>– рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерми торган ысуллар ярдәмендә башкарыла (6 пункт);<br>– вакытлы корылмаларны, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техника корылмаларын вакытлыча урнаштыру барыннан элек агачсыз һәм куаксыз урыннарда, ә мондый урыннар булмаганда – артык кыйммәтле булмаган агачлар белән капланган, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә (8 пункт). |
| 9. | Урман плантацияләре утырту һәм аларны эксплуатацияләү | Плантация ясау максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми:<br>а) су саклау зоналарында урнашкан урманнарны;<br>б) табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарны;<br>в) кыйммәтле урманнарны;<br>г) махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны. |
| 10. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | 2011 елның 05 декабрендәге 510 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>– җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, шулай ук урманга әверелмәгән диләнкеләр, аланнарны һәм аларга |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | урман культураларын утырткачны урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар һ.б.) (11 пункт) җирләр файдаланыла.<br>– җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен –үстерү өчен үзгәртеп коруга билгеләнмәгән, азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин (12 пункт);<br>– Россия Федерациясе Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану тыела. |
| 11. | Урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү | 2011 елның 19 июлендәге 308 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалын үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урманнар урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла (11 пункт);<br>урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла (12 пункт);<br>урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела (13 пункт);<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә тыела. |
| 12. | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару | Яшел зоналарда һәм урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда файдалы казылма ятмаларын эшкәртү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешенең 4 пункты, 4 өлешенең 1 пункты).<br>Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатында урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бульдозер ярдәмендә агачлар аудару һәм урман |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудa чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызындагы агач кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда яңа киселгән агачларны махсус чараларсыз гына урманда саклау;<br>б) урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;<br>в) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфракны зарарлау;<br>г) урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач, көнкүреш һәм бүтән калдыклар, чүпләр белән чүпләү;<br>д) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>е) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап, шул исәптән урман кишәрлегеннән читтә транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (2010 елның 27 декабрендәге 515 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча файдалану тәртибенең 18 пункты). |
| 13. | Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендәге 5 пункты). |
| 14. | Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү | Урманнарны линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм тапшырылган урман кишәрлегеннән читтәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) тапшырылган урман кишәрлеге һәм тиешле сак зоналарыннан читтә ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (2011 елның 10 июнендәге 223 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләренең 15 пункты).<br>Урман паркы зоналарында урманнарда линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм алардан файдалану максатларында |

| т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | урманнардан файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 5 пункты). |
| 15. | Агач һәм башка урман ресурслары эшкәртү | Яклагыч урманнарда, шулай ук махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы ясау тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 14 статьясының 2 өлеше).<br>Урманнарны үзагач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) җир өсте һәм туфрак эче су агынтыларын бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә янәшә торучы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2014 елның 1 декабрендәге 528 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 6 пункты). |
| 16. | Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру | Дини эшчәнлек башкарганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә өске һәм туфрак эче сулары агып төшүне бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>г) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда үтеп керү. |

Гамәлдәге урман орлыкчылык объектларының нормативлары һәм параметрлары әлеге урман хуҗалыгы регламентында әзерләнми, урман орлыкчылык объектлары турында белешмәләр ел саен Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Дәүләт урман реестрын алып бару формаларын раслау турында» 2016 елның 06 октябрендәге 514 номерлы боерыгы белән расланган 14-ДУР формасы буенча яңартыла.